КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 август г.Казань № 669

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 апрель, 683 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәдә:

6 бүлекнең 6.6 пунктындагы 5 пунктчаның дүртенче, бишенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

9 бүлекнең 9.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.9. Конкурс комиссиясе номинацияләрнең берәрсендә урын(нар) бирмәү турында карар кабул итсә, призларга бүлеп бирелгән акча оештыручы тарафыннан тигез өлешләрдә башка номинацияләрдә шул ук урыннарны алган җиңүчеләр арасында бүленә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 2 декабрь, 885 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча
конкурс комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе |
| Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисенең мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек буенча урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шакирова Регина Ришад кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының матбугат хезмәтләре белән эшләү һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге баш белгече, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әдиятова Әлфия Нәби кызы | «ТАТМЕДИА» акционерлар җәмгыятенең басма массакүләм мәгълүмат чаралары буенча генераль директор урынбасары (килешү буенча) |
| Әмирова Айгөл Тәлгать кызы | «Телевизион яңалыклар хезмәте» мәгълүмати-телевизион агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте программаларын алып баручы (килешү буенча) |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Беляков Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гарифуллин Васил Заһит улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең массакүләм коммуникацияләр бүлеге җитәкчесе, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге Президиумы әгъзасы (килешү буенча) |
| Гыйниятов Данил Шамил улы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте башкарма директоры – баш мөхәррире урынбасары (килешү буенча) |
| Козлов Вадим Евгеньевич | «Педагогика, психология һәм социаль проблемалар институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Сабирова Гөлнара Ильяс кызы | «Ватаным Татарстан» газетасы баш редакторы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча). |